# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Илбәк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**19 сентябрь 2025 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, "2024 елның 22 ноябрендәге 1нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», 2024 елның 22 ноябрендәге 2 нче номерлы «2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында» карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең Илбәк торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында” Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге башлыгының 2025 елның 08 сентябрендәге 5 номерлы карары нигезендә 19.09.2025 елда узган гражданнар җыены нәтиҗәләре беләң гражданнар Җыенының түбәндәге мәсьәлә буенча йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«22.11.2024 ел, №1 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең Илбәк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», 22.11.2024 ел, № 2 «Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең Илбәк торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында» карарларына, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә ризамы?:

« - Илбәк торак пунктында урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу, алмаштыру);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту (Илбәк авылында Ә. Вәлиев урамындагы 35 нче йорттан 39 нчы йортка кадәр вак таш түшәлгән юлны профильләштерү);

- Илбәк торак пункт территориясен төзекләндерү (тракторчыга механикалаштырылган кар җыю буенча хезмәтләр өчен түләү, торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту буенча чит оешмалар хезмәтләре).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 130 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 68.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен – 68, «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирүче юк.

Бәян ителгәннәр нигезендә, **гражданнар җыены карар итте**:

1. Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип таныргa.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип таныргa:

22.11.2024 ел, №1 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең Илбәк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», 22.11.2024 ел, № 2 «Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең Илбәк торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында» карарларына чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә ризамы?:

« - Илбәк торак пунктында урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу, алмаштыру);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту (Илбәк авылында Ә. Вәлиев урамындагы 35 нче йорттан 39 нчы йортка кадәр вак таш түшәлгән юлны профильләштерү);

- Илбәк торак пункт территориясен төзекләндерү (тракторчыга механикалаштырылган кар җыю буенча хезмәтләр өчен түләү, торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту буенча чит оешмалар хезмәтләре)».

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Илбәк авылы, Ә.Вәлиев ур., 10а йорт; Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендынларында урнаштырырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге башлыгы Р.К.Галимҗанова